

# Исәнме,
# балалар бакчасы!

**Әти-әниләр өчен кулланма (4-5 яшь)**

## Җырлар, юаткычлар, эндәшләр

Кояшкаем, чык, чык,
Майлы ботка бирермен.
Майлы ботка казанда,
Тәти кашык базарда.
Әти китте базарга,
Тәти кашык алырга.
Тәти кашык сабы алтын,
Безгә кирәкми салкын.

Утыр, балам, ашарга,
Түгеп-чәчеп ашама.
Матур утыр табында,
Алдыңа күл ясама
Ипи валчыгыңны койма,
Аяк астына ташлама.

Чума үрдәк, чума каз,
Тирән күлне ярата ул,
Тирән күлне ярата,
Әлфирә үзенә иптәш эзли,
Белмим, кемне ярата шул,
Белмим, кемне ярата.
Сәвияне ярата шул, ярата.

Әй чулпысы, чулпысы,
Бигрәк матур тәңкәсе.
Аккош микән, былбыл
микән.
Моны тапкан әнкәсе.

## Шигырьләр

***Бакчага килгәч***

Безне бик яраталар
Бакчадагы апалар:
Килгәч тә елмаеп,
Кулларын киң җәеп
Кочаклап алалар, —
Әниләр күк алар...
*Бари Рәхмәт*

***Уенчыклар***

Без уйныйбыз залда,
Ни генә юк анда:
Тун кигән аюлар,
Әтәчләр, тавыклар,
Кыланчык маймыллар,
Кәҗәләр, сарыклар.
Тиеннәр, керпеләр,
Батыр без —
курыкмыйбыз
***Бари Рәхмәт***

**Мәкальләр**

*Бит күрке — күз, тел күрке — сүз.
* Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел.
* Сүз бирсәң — үтә.
* Ничек эндәшсәң, шулай ишетерсең.
* Аз сөйлә, күп бел.

**Чебиләр сөенделәр**

Ишегалдында иртән Бик
җәлләдем мин аны, Сап-
сары күлмәк кигән Аннан
тотып сак кына, Нәни генә
бер чеби Илтеп куйдым
чебине Аптырап елап
йөри. Башкалары янына.
Корт эзләп бара-бара,
Иптәшләре табылгач,
Ераккарак киткән ул. Бар
да бик сөенделәр.
Иптәшләрен югалткан Һәм
чебиләр телендә: Һәм
адашкан икән ул. «Рәхмәт
сиңа!» — диделәр.

***Ямаш Игәнәй***

| | |
|---|---|
| **Хәрәкәтле уеннар**<br>***Тота бел***<br>Балалар тәрбияче белән бергә түгәрәкләнеп тезеләләр һәм бер-берсенең кулларына тотынышалар. Түгәрәк уртасына әйдәүче баса. Балалар түгәрәк буенча уңга яки сулга таба әйләнеп йөриләр һәм түбәндәге сүзләрне көйләп әйтәләр: “Без, балалар,<br>яратабыз уйнарга, йөгерергә, җырларга, әйдә, безне куып кара, көчең җитсә тотарга, Тот!” Соңгы «Тот!» дигән сүзне әйтү белән, балалар мәйданчык (бүлмә) буйлап йөгерә башлыйлар, әйдәүче аларны куып тотарга тырыша. Тотылган балалар вакытлыча уеннан чыгалар. Әйдәүче 3–5 баланы тоткач, уен тәмамлана. Уйнаучылар арасыннан яңа әйдәүче сайлана (тотылган балалар сайлана алмый). Яңа уенга үткән уенда тотылган балалар барысы да яңадан катнаша. Уен 3–5 тапкыр кабатлана.<br>**Җитез балалар**<br>Балалар урындыкларда утырып торалар. Идәнгә куелган кәрзингә уртача зурлыктагы 5–6 туп салына. Балаларның бер өлеше (туп санына карап), утырган урыннарыннан торып, бер рәткә тезеләләр. Тәрбияче: «Бер, ике, өч», – ди дә кәрзиндәге тупларны тәгәрәтеп җибәрә. Балалар туплар артыннан йөгерәләр. Һәр бала бер тупны тотып, тәрбиячегә китереп бирә. Тәрбияче балаларны мактый. Туплар артыннан йөгергән балалар үз урыннарына килеп утыралар, ә алар урынына башка балалар чыга. | |



# *Өлкәннәргә хөрмәт*

***Әти-әниләр өчен кулланма(4-5 яшь)***

***Җырлар, такмаклар, мавыктыргычлар, эндәшләр,***

Утыр, балам, ашарга,
Түгеп-чәчеп ашама.
Матур утыр табында,
Алдыңа күл ясама.
Ипи валчыгыңны койма,
Аяк астына ташлама

*Әй чулпысы, чулпысы,
Бигрәк матур тәңкәсе.
Аккош микән, былбыл микән
Моны тапкан әнкәсе.

***Дәү әнигә күчтәнәч***

Тутырдык без тартмага
Өрек, йөзем, алманы,
Салдык чәй дә, конфет та
Буш урыннар калмады.

Әй сөенер дәү әни,
Килеп төшкәч күчтәнәч.
Кызык булыр ул аңа,
Алдан белеп көтмәгәч.

Шәүкәт Галиев

## Мәкальләр

Картлар сүзен капчыкка сал, яшьләрнекен янчыкка сал.

Олының сүзен оекка кыстыр.

Картлар сүзен кар басмас.

Олыласаң олыны, олыларлар үзеңне.

### Төлке һәм куяннар

Идәнгә зур түгәрәк сызыла. Ул — «куян балаларының оясы». Бер читтә «төлке» утыра. Балалар ояларыннан чыгып сикерәләр, уйныйлар, бииләр. Тәрбияче: «Төлке килә!» — диюгә, балалар ояларына йөгерәләр. «Төлке» аларны куа. Уен шулай дәвам итә.

### Кечкенә туплар

Балалар, түгәрәк ясап, урындыкларда утырып торалар.

Рәттән утырган 2 балага тәрбияче берәр кечкенә туп бирә. Бер бала тупны уң якка, икенчесе сул якка җибәрә (балалар тупларны бер-берләренә бирәләр). Ике туп «очрашкач», туплы балалар икесе ике якка йөгереп китәләр. Калган балалар бу вакытта «йөгердек, йөгердек» дип кабатлыйлар, кулларын чәбәклиләр. Ике бала, кара-каршы очрашкач, тупларын тәрбиячегә тапшыралар. Ул аларны башка балаларга бирә һәм уен дәвам итә.

| **Хәрәкәтле уен «Бабай һәм оныклар».** Бер бала – бабай, калганнары – оныклар; бабай өйдә утыра, ә оныклар өйдән читтәрәк нәрсә эшләячәкләре турында сөйләшәләр. Мәсәлән: бакчада җир казыдык, оекбаш бәйләдек, кер юдык һ.б. Аннары бабай янына киләләр, бабай алардан: «Сез кайда булдыгыз?»- дип сорый. Балалар: «өйдә», «урманда», «бакчада» һ.б. дип җавап бирәләр. Бабай: «Сез анда нишләдегез?»- ди. Балалар бергәләп бертөрле хәрәкәт белән нәрсә эшләгәннәрен күрсәтәләр. Бабай белергә тиеш. Дөрес җавап әйтелгәч, балалар йөгерәләр, бабай аларны куа. Беренче тотылган бала бабай була. | |
|---|---|



# *Бакчадагы һөнәрләр*

***Әти-әниләр өчен кулланма(4-5 яшь)***

***Табыышмаклар***

Сакалы бар, кашы юк,
Гәүдәсе бар, күзе юк.
Сакалын җирдән сөйри,
Бүлмә эчендә йөри. (Себерке.)

Йөри-йөри паластан,
Эшли ул гел уттан.
Ул эшләсә, тузан юк,
Анының да тамагы тук.
(Тузан суырткыч.)

Шкафны да сөртә ул,
Идәнне дә житешә. (Чүпрәк.)

Аңа су да салалар,
Аңа чүп тә салалар.
Ул комны да, керне дә,
Ни салсаң да күтәрә. (Чиләк.)

| | |
|---|---|
| **Мәкальләр**<br>Хезмәт төбе — хәзинә.<br>* Эше барның ашы бар.<br>* Тирләп эшләсәң, тәмләп ашарсың.<br>* Бакча ясамый, алма булмый.<br>* Эшләп ашасаң, һәр ризык балдай татлы була.<br>* Агачны яфрак бизәсә, кешене хезмәт бизи.<br>* Тырышкан табар, ташка кадак кагар.<br>* Биш әйткәнче, бер эшлә.<br>* Сүзең белән мактанма — эшең белән мактан.<br><br>***Һаҗирә апа***<br>Әү менә минем апа<br>Конфет-перәнник сата.<br>Ул эшләгән кибеттә<br>Бар ак күмәч тә, сөт тә.<br>Әйбер ала күп кеше<br>Олысы һәм кечесе.<br>Һәммәсе мактап китә,<br>Апамны хөрмәт итә.<br>Мөхәммәт Садри | |
| ***Тизрәк урыныңа бар***<br>Уен балаларны урында ориентлашырга, ритм хисен тоярга, тигез хәрәкәтләр ясарга өйрәтә. Тәрбияче балаларны колоннага тезә, аннан соң алга басып, үзе балалар белүн бергү атлап йөри башлый. Балалар тигез атлап йөрсеннәр өчен, ул башта кул чаба һәм шул ук вакытта: «Бер-ике, бер-ике, бергә!» – дип әйтә, аннан соң, балаларның атлавына туры китереп, аларга таныш булган нинди дә булса бер җыр җырлый башлый. Җырның бер куплетын яки бөтенесен җырлап бетергәч, тәрбияче кисәктән генә: «Тизрәк урыныңа бар!» – дип кычкыра, һәм балалар барысы да урыннарына йөгерәләр. Тәрбияче башкалардан алда йөгерүче бала- ларны үз урынына билгеләп куя. | |

***Атлар һәм көтүче***

Балалар атлар итеп билгеләнәләр, тәрбияче — көтүче. Ул, курай уйнаган хәрәкәтләр ясый-ясый, түбәндәге шигырь юлларын сөйли:

Курай уйныйм: та-ра-ра!
Атлар кай якка таба бара?
Атлар бара болынга,
Яшел чирәм ашарга.

Бу вакытта балалар, бер аякларын алга, икенчесен артка куеп, атлар кебек сикергәләп, мәйданчык буйлап йөриләр. Курай уйнаудан туктагач, «атлар» да туктап калалар, башларын селкеп торалар. Тәрбияче кабат курайда уйный һәм уен кабатлана.



# ***Көз***

***Әти-әниләр өчен кулланма(4-5 яшь)***

Кырлар буш кала,
Яңгырлар ява.
Җирләр дымлана.
Бу кайчак була? (Көз.)

***

Сап-сары яфраклар
Җил искәч очалар.
Бөтерелә-бөтерелә
Җиргә үк төшәләр.

***

Көз килде. Үләннәр
Саргайды, шиңде.
Сап-сары яфраклар
Җиргә сибелде.

***

Бер кошка кызыгамын:
Тәпие кызыл аның.
Атлаган саен баш ия –
Гадәте кызык аның.
Гөлдер-гү, гөлдер-гү,
Бигрәк чибәр, кемдер бу?

| | |
|---|---|
| **Мәкальләр**<br>Көз бай булма, яз бай бул.<br>Көз кычкыра: «Уңдырам»,— дип, ә яз әйтә: «Тукта әле, мин нәрсә әйтермен»,— дип.<br>Көзге көн ул бала кебек: әле көлә, әле елый.<br>Күз өчен яз яхшы, авыз өчен көз яхшы.<br>Көзге көннән язгы төн яхшы.<br>Көзге юлга кием ал, язгы юлга азык ал. | |
| ***Курыкмыйм***<br>Балалар түгәрәк ясап басып торалар. Бер бала әбәкләүче итеп билгеләнә. Ул түгәрәк уртасына баса. Балалар, «курыкмыйм! Курыкмыйм!» дия-дия, бер урында ике аякта сикерәләр. Бу вакытта алар кулларын әле як-якка җәяләр, әле артларына яшерәләр. Әбәкләүче, балалар кулларын як-якка җәйгәндә, аларны әбәкләп өлгерергә (кулы белән кагылырга) тырыша. Әбәкләнгән бала уеннан чыгарыла. | |

**Җырлы-биюле уен «Куш кулым».**

Урман буйларына менәм
Урман буе ямьлегә.
Бир кулыңны, мин
дә бирәм,
Дус булырга мәңгегә.
Менә сиңа уң кулым,
Менә сиңа сул кулым.

Уң кулым да, сул кулым,
Менә сиңа куш кулым.
Алма бакчасына кереп,
Алма ашыйсым килә.
Син алмасы, мин чәчәге
Булып яшисем килә.



# *Минем өй, минем бистә, минем республика*

***Әти-әниләр өчен кулланма(4-5 яшь)***

**Туган илнең улы мин**

Бабайның да
Улы мин,
Әбинең дә
Улы мин,
Әтинең дә
Улы мин,
Әнинең дә
Улы мин,
Аларның уң кулы мин.
Бабай кебек
Булырмын,
Әби кебек
Булырмын,
Әти кебек
Булырмын,
Әни кебек
Булырмын,
Бернигә дә карамый.
Шулай булмый
Ярамый —
Соң бит инде
Олы мин,
Туган илнең
Улы мин!

Роберт Миңнуллин

| | |
|---|---|
| **Табышмаклар**<br><br>* Көн-төн йөри,<br>Урыныннан китә алмый.<br>(Сәгать)<br>* Почмакта бер суык кыш,<br>Исеме аның... (суыткыч).<br>* Төймәсенә басу белән<br>Бәйли зәңгәр яулыгын.<br>Аш пешерә, чәй кайната —<br>Күрсәтә уңганлыгын.<br>(Газ плитәсе)<br><br>*Сөйләп бирә тел белән,<br>Сүзе китә юл белән,<br>Юлы агач башында. (Телефон)<br>* Үзе бер әрҗә,<br>Бөтен дөньяны<br>Күрсәтә. (Телевизор)<br>* Аяксыз, кулсыз<br>Өй саклый.<br>(Йозак) | |
| ***Тилгән һәм тавык***<br>Уен мәйданчыгының бер башында җиргә түгәрәк сызыла. Ул — «тилгән оясы». Уенда катнашучыларның берсе — «тилгән», икенчесе «тавык» итеп билгеләнә. Калган балалар «чебиләр» булалар. «Чебиләр» бер-берләренә тотынып, «тавык» артына те- зелеп басалар (алда торучы «чеби» «тавыкка» тотына). Уенны алып баручы «тилгән килә» дип сигнал бирә. «Тилгән» оясыннан чыга да колоннада соңгы булып басып то- ручы «чеби»не тотарга тырыша. «Тавык», «канатларын җәеп» (кулларын як-якка сузып), балаларын саклый. Ул «тилгән» кай- сы якка ташланса, шунда «тилгән»гә каршы чыга. Бу вакытта «чебиләр», бер-берләреннән аерылмыйча, «тавык» артыннан ияреп йөриләр, соңгы булып басып торучы «чеби»не тоттыр- маска тырышалар. Әгәр «тилгән» иң арттагы баланы тартып ала алса, ул аны үз оясына алып китә. Уен вакытында балалар чылбырны ычкындырмаска, «тавык»тан аерылмаска тырышалар. | |



# *Куркынычсызлык кагыйдәләре*

## *Әти-әниләр өчен кулланма(4-5 яшь)*

***Светофор— тәмлетамак?!***

Светофордан сорадым бүген:
– Нигә кып-кызыл
Синең бер күзең?
Елмаеп, миңа
Ул болай диде:
– Кызыл помидор
Ашаган идем...
Светофордан
Сорадым тагы:
– Икенче күзең
Нигә сап-сары?
Елмаеп, янә
Ул болай диде:
– Иртән лимонлап
Чәй эчкән идем...

Сорамый тагы
Буламы түзеп:
– Нигә ямь-яшел
Өченче күзең?
Балкып елмайды
Һәм әйтте аннан:
– Ашаган идем
Ямь-яшел алма...
Шаярта ла ул –
Беләм ич инде!
...Шулай да торам
Ялмап иренемне.

Ләбиб Лерон

## Мәкальләр

*Аюдан курыксаң, урманга барма,
*Бүредән курыксаң, сарык асрама.
* Ике куянны берьюлы кумыйлар.
* Юлда йөрергә дә акыл кирәк.
* Урау булса да, юл яхшы.
* Юлга чыксаң, азыгың үзең белән булсын.

## Табышмаклар

* Авызы юк, борыны юк,
Тик бар аның өч күзе.
Урамдагы хәрәкәтне
Көйләп торадыр үзе.
(Светофор)
* Башыбыз бар, гәүдәбез бар,
Юк кул, аякларыбыз.
Балалар тотса куркабыз —
Яман шул якларыбыз.
(Шырпы)
* Сукмактан да чыгалмыйлар,
Бер-берсен дә уздырмыйлар,
Кызыл күзле ябалактан
Рөхсәт алмый кузгалмыйлар.
(Трамвай, светофор)

* Пожар турында ишеткәч,
Сигнал бирергә ашык.
Янгын гел көчәя бара,
Туктатып булмый ич һич.
Су гына сүндермәс аны,
Кирәк шул... (ут сүндергеч).
* Автомобиль, трамвайдан
Саклан, димен, бик сак бул!
Уйный торган урын түгел
Машиналар йөргән... (юл).
* Җәен, кышын, яз, көзен,
Иртән, кичен, көндезен
Телсез әйтәдер сүзен —
Ача-йома өч күзен.
(Светофор)

| | |
|---|---|
| **Туп белән куышу**<br>Балалар түгәрәк ясап басалар. Түбәндәге сүзләрне әйтә-әйтә, тупны түгәрәк буенча җибәрәләр (бер-берсенә бирәләр):<br>Бер, ике, өч,<br>Дүрт, биш, алты,<br>Туп кемдә калды?<br>– Миндә!<br>Соңгы сүз туры килгән бала, «Миндә!» дип, тупны югары күтәрә һәм аны балаларның аякларына ыргыта. Аягына туп тигән бала уеннан чыга. 3–5 бала «тотылгач», уен тәмам була. Кабатлап уйнаганда, тупны икенче юнәлештә җибәрәләр. | |
| **Өрел, куык!**<br>Балалар түгәрәккә тезелеп басалар. Башларын алга ия төшеп, берсен икенчесе өстенә куйган йодрыкларына һава өрәләр – «куык кабарталар». Башларын турайтып, эчләренә һава алалар да яңадан, иелеп, «ф-ф-ф» дип, «трубка» эченә һава тутыралар (2 тапкыр кабатлана). Һәр өргән саен, бер адым артка атлыйлар (куык кабара бара). Шул рәвештә бу күнегү 2–3 тапкыр кабатлана. Аннан соң, бер-берсенең кулларына тотынган хәлдә, түбәндәге сүзләрне әйтә-әйтә артка чигенә барып, түгәрәкне киңәйтәләр:<br>Өрел, куык, зур булып,<br>Тик шартлый күрмә тулып;<br>Һаман да бул син матур –<br>Кабарынып тор да тор!<br>Җөмләнең ахыргы сүзләрен әйткәндә, куык (түгәрәк) зур булып җитешә. | |



# *Кеше һәм предметлар дөньясы*

*Әти-әниләр өчен кулланма(4-5 яшь)*

**Кәгазь**

Без укый торган китаплар,
без яза торган дәфтәрләр,
без карый торган альбомнар
башта — агач булганнар.
Яфрак ярып, җилдә шаулап,
Җирдә басып торганнар.

Аннан аларны екканнар,
чапканнар да кискәннәр...
Машиналардан үткәреп,
юка кәгазь иткәннәр.
Алдымда — чиста ак кәгазь,
Нинди агачтан икән?

Каеннанмы, нараттанмы,
әллә усактан микән?
Аның урынына яңаны
кемдер утырткан микән?..
...Уйлап тордым да ясадым
кәгазьгә бер имәнне.

Ясадым мин имәннең
шәбен — менә дигәнне!
Очы күккә тигәнне,
мәңге үсеп торырлыкны.
— Кош оя корырлыкны.
Күргән кеше шатлансын.

Кәгазьдә генә булса да,
тагын бер агач артсын!

*Равил Фәйзуллин*

## Мәкальләр

* Китап — белем чишмәсе.
* Китап галим — телсез мөгаллим.
* Китапның белмәгәне юк.
* Китапсыз өй — ишәк абзары.
* Үзеңнең надан икәнеңне беләсең килсә, күп китап укы.

## Табышмаклар

* Кышын да, җәен дә бертөсле.
(Чыршы, нарат)
* Ап-ак күлмәген кигән,
Күлмәгенә тап тигән.
(Каен)
* Озын, яшел — түтәлдә,
Сары, тозлы — кисмәктә.
(Кыяр)
* Үсеп утыра бер чүлмәк,
Өстенә кигән йөз күлмәк.
(Кәбестә)
* Нинди агач җилсез шаулый?
(Усак)
* Алсу битле кыз үсте,
Кызарып, җиргә төште. (Алма)
* Җир астында җиз бүкән,
Һәр көн ашыйсың, иркәм. (Бәрәңге)
* Туп түгел — түгәрәк,
Күсе түгел — койрыклы. (Чөгендер)
* Кызыл төймә таптым,
Авызыма каптым.
(Җиләк)

| | |
|---|---|
| **Туп кайда?**<br>Санамыш ярдәмендә уенны алып баручы сайлана. Балалар түгәрәккә басалар. Алып баручы уртада басып тора. Уйнаучылар, алып баручыга сизелмәслек итеп, арттан туп бирешәләр. Әгәр алып баручы тупның кемдә икәнен сизсә, аның янына килеп: «Кулларыңны күрсәт», – ди. Әлеге бала, учларын өскә каратып, кулларын югары күтәрә. Әгәр аның кулында туп булса (яки ул тупны төшереп җибәрсә), уен тәмам була. Әгәр туп анда булмаса, ул кулларын яңадан артка куя, һәм уен дәвам итә. Туп белән 2–3 бала тотылгач, алып баручы алышына. | |
| **Тупны җибәрмә!**<br>Балалар, бер-берсенә кул сузарлык ара калдырып, түгәрәккә тезеләләр дә кулларын артка куеп, җилкә киңлегендә аякларын аерып басалар. Әйдәүче түгәрәк уртасына керә һәм тупны кайсы да булса бер уйнаучының аяк арасыннан тәгәрәтеп җибәрергә тырыша. Туп үзенә таба тәгәрәп килгән бала, аякларын тиз генә янәшә куеп, аны аяклары арасыннан чыгармаска тиеш. Тупны аяк арасыннан үткәргән бала түгәрәктән бер адым артка китә. 2–3 бала тупны аяклары арасыннан җибәргәч, уен тәмамланган санала. | |



# Исәнме, Яңа ел!

**Әти-әниләр өчен кулланма(һ4-5 яшь)**

***Кыш бабай***

Җилкәсенә капчык асып,
Кыш бабай килеп керде.
Төрле кызык сүзләр әйтеп,
Бүләк өләшеп йөрде.

Аннан Кыш бабай тыпырдап,
Бик шәп бии башлады.
Биемәскә, аягында —
Безнең апа башмагы.
Мәрзия Фәйзуллина

**Һай, Кыш бабай**

Кемнең кигән киемнәре
Кем соң безгә шундый ямьле
Энҗе кар бөртекләре? Яңа ел алып
килә? Кемнең көмеш күк сакалы,
Матур-матур капчыкларга
Чәчләре, керфекләре?
Күчтәнәч салып килә?
Ә дигәнче үсте бабай —
Үзебездән дә биек.
Эчкә сыймый шатлыгыбыз —
Киттек тирәли биеп.
Чаңгы-чанада шуарга
Булды шома тавыбыз.
Кем безгә аны ясаган,
Кем икән ул, табыгыз...

*Җәвад Тәрҗеманов*

**Табышмаклар**

*Үзе кардай ап-ак ул,
Озын колак бик сак ул.
Дошман күрсә элдертә,
Кем аны куып җитә?
(Куян)

* Ул өстенә җәй дә, кыш та
Энәле күлмәк кия.
Шулай да аны әнкәсе
«Йомшагым» диеп сөя.
(Керпе)

* Асрамый да умарта,
Балны бик, бик ярата.
Кышын сөя йокыны,
Язгача тормый ята. (Аю)

* Үзе ялагай,
Үзе хәйләкәр.
Ул нәрсә булыр,
Йә, әйтеп җибәр. (Төлке)

* Сорыдыр төсе,
Үткендер теше,
Урманда йөри,
Бозаулар күзли. (Бүре)

**Куышу**

Уен мәйданчыгының каршы якларына ике туры сызыла. Болар – балаларның «өйләре». Барлык балалар бер туры сызыкның артына (өй эченә) басалар. Турылар арасында уйнаучыларның берсе басып тора. Өй эчендә торучы балалар түбәндәге сүзләрне әйтәләр: Без, балалар, яратабыз йөгереп, сикереп уйнарга. Әйдә, безне куып кара, Көчең җитсә тотарга, Тот! Тәрбиячеңең «Бер, ике, өч, инде монда көч!» дигән сүзеннән соң барысы да, өйдән чыгып, каршыдагы өйгә йөгерәләр. Ике өй арасындагы бала йөгерүче балаларны тота. 2–3 бала тотылганнан соң, икенче тотучы сайлана, һәм уен яңадан башлана.

| ***Аучы һәм ерткыч җәнлекләр***<br>Уйнаучылар арасыннан бер бала «аучы» итеп билгеләнә. Ул бүлмәнең бер почмагында тора. Балалар – урмандагы «җәнлекләр»: «төлкеләр», «куяннар», «аюлар», «бүреләр», алар төркемнәргә бүленеп, бүлмәнең төрле җирләренә урнашалар. Аучының кулында ике кечкенә туп. Ул урманда җәнлекләрне караштырып йөри һәм, берникадәр йөргәч, ял итәргә утыра. Шулвакыт тәрбияче: «Куяннар, төлкеләр чыктылар», – ди. Бу сүзләрне ишетүгә, үз исемнәре әйтелгән җәнлекләр өннәреннән чыгалар (балалар аларның характерлы кыланышларын күрсәтеп йөриләр. Мәсәлән, куяннар ике аякта сикерәләр, төлкеләр койрыкларын болгап йөриләр. Тәрбияче: «Аучы!» – диюгә, барлык җәнлекләр өннәренә таба йөгерәләр, ә аучы аларны «ата» – тупларны бер-бер арт- лы ыргыта. Туплар кемгә дә булса тисә, шуны, алып китеп, «читлеккә» (билгеләнгән урынга) утырта. Аучы 3–4 җәнлекне аткач, яңа «аучы» сайлана, уен яңадан башлана. | |
|---|---|



# Кыш

## Әти-әниләр өчен кулланма(4-5 яшь)

### Җырлар, юаткычлар, эндәшләр

Утыр, балам, ашарга,
Түгеп-чәчеп ашама.
Матур утыр табында,
Алдыңа күл ясама
Ипи валчыгыңны койма,
Аяк астына ташлама.

Әй чулпысы, чулпысы,
Бигрәк матур тәңкәсе.
Аккош микән, былбыл
микән.
Моны тапкан әнкәсе.

### Табышмаклар

Тәңкә карлар сипкән,
Җирне ап-ак иткән,
Чыршы, каен, имән
Кардан чикмән кигән.
Бу кайчак? (Кыш)

Колак, борынны уып,
Өеңә кертә куып (Салкын)

Ишегалдында таш була,
Өйгә керсә, су була (Боз)

## Шигырьләр

***Кыш***

Уянып бүген иртән
Карасам тәрәзәгә,
Ак сакаллы Кыш бабай
Кар алып килгән безгә.

Әйдәгез, тауга барыйк,
Чанада шуып калыйк.
Бер тузан юк, саф һава,
Җиргә ап-ак кар ява.

Җәвад Тәрҗеманов

***Шуабыз***

Чанада да шуабыз,
Чаңгыда да шуабыз.
Тимераякта очабыз,
Чыңлап тора шома боз.

Тауларга да барабыз,
Кырларга да чыгабыз.
Кар-буран дип тормыйбыз,
Шуабыз да шуабыз.

Нәҗип Мадьяров

## **Үстерешле уеннар**

### **Матур уен**

Балалар кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар. Бер бал уртага баса

Син уртада без кырыйда
Әйләнәбез түгәрәк.
Уеныбыз матур булсын,
Күңел ачыйк бергәләп.

*Балалар түгәрәк буйлап җырлап йөриләр,*

Таянабыз билләргә,
Тотынабыз биергә.

*туктап, түгәрәк уртасына борылалар, кулларын билгә куялар,*

Тыпыр-тыпыр тыпырдатып
Әйләнәбез без бергә.

*аякларын тыпырдаталар, парлашып әйләнәләр.*

| | |
|---|---|
| **Хәрәкәтле уеннар**<br>***Кыңгырау***<br>Балалар, түгәрәк ясап, идәнгә тезләнәләр. Бер бала, матур көй астында кыңгырауны шалтыратып, түгәрәк буйлап йөри. Көй туктаганда, кыңгырауныбер баланың артына идәнгә куя. Барлык балалар да борылып карыйлар. Артына кыңгырау куелган бала йөгереп китә. Каршы якка кыңгырау куючы бала йөгереп китә. Кем беренче килеп җитә, шул, кыңгырауны алып, уенны дәвам итә.<br>**Әбәк**<br>Уен бер төркем балалар арасында уйнала. Арадан бер бала икенче баланың аркасына, йомшак кына итеп, әбәк, дип, тиз генә суга да үзе бер якка кача. Сугылган бала, икенче берәүне куып җитеп, әбәкне кайтарырга тиеш. | |



# *Мин сәламәт булып үсәм*

***Әти-әниләр өчен кулланма(4-5 яшь)***

## ***Җырлар, юаткычлар, эндәшләр***

Утыр, балам, ашарга,
Түгеп-чәчеп ашама.
Матур утыр табында,
Алдыңа күл ясама
Ипи валчыгыңны койма,
Аяк астына ташлама.

Бас, кызым, эзенә,
Күз тимәсен үзеңә;
Асыл гөлләр үсеп тора.
Синең баскан эзеңә

## ***Табышмаклар***

Исе юк, төсе юк,
Аннан башка тормыш юк. (Су)

Лампа түгел – яктырта,
Мич түгел - җылыта

Ипи түгел, су түгел,
Авыр түгел, аз түгел,
Ансыз яшәү мәмкин түгел (Һава)
Бит-кулыңны югач, сиңа мин кирәк.
Мин нәрсә булам, әйт тизрәк
(Сөлге)

Шигырьләр

***Чисталык сөябез***

Иртә белән торабыз,
Битебезне юабыз.
Сабын белән юынгач,
Бигрәк матур булабыз.

Муеныбызны юабыз,
Тешләрне чистартабыз.
Пөхтәлекне, чисталыкны
Һәрвакыт яратабыз.

Аш алдыннан һәрвакыт
Кулыбызны юабыз.
Ап-ак итеп кулны юып
Ашарга утырабыз.

Аякларны кичкырын
Сабын белән юабыз.
Юынырга яратабыз,
Без бик чиста торабыз.

Әхмәт Ерикәй

**Мәкальләр**

*Саф һава – тәнгә дәва.
*Сәламәт тәндә – сәламәт акыл.
* Таза тәндә – таза рух.
*Чисталык – сәламәтлек билгесе.
*Шапшак – ялкауның юлдашы.

**Үстерешле уен “Без урманга барган идек...”**

Балалар түгәрәктә басып торалар. Бер бала башкаларга арты белән баса. Тәрбияче күз караша белән генә түгәрәктәге бер балага ымлый. ул икенче бүлмәгә чыга. Балалар бергәләп кабатлыйлар:
Без урманга барган идек, югалттык беребезне,
Әйтеп бирче безгә, Риназ, югалттык соң без кемне?
Риназ, борылып карап, кем юклыгын әйтә. Дөрес әйтмәсә, тагын бер кат сынап карыйлар, дөрес әйтсә, урыннарын алышалар.

| | |
|---|---|
| **Хәрәкәтле уеннар**<br>***Беренче булып бас***<br>Балалар бер-бер артлы тезелеп басалар. Тәрбиясенең сигналы буенча йөгереп китәләр, йөгерү барышында тәрбияче бер баланы исеме белән атый. Исеме әйтелгән бала колоннадан чыга һәм, йөгереп, колоннаның башына барып баса. Уен шулай дәвам итә.<br>**Шалтыравыклар.**<br>Бүлмәнең бер башында сызык сызыла. Аның артына 5-6 бала баса. Каршы яктагы урындыкларга шалтыравыклар куела. Тәрбиясенең “Бер, ике, өч! Йөгерергә кирәк көч!” дигән сигналыннан соң, балалар каршы якка таба йөгерәләр һәм шалтыравыкны йөгереп килеп алалар, баш өстенә күтәреп шалтыраталар. Иң беренче булып йөгереп килгән бала җиңүче була. | |



# *Кеше һәм әйләнә-тирә дөнья*

*Әти-әниләр өчен кулланма(4-5 яшь)*

## *Җырлар, юаткычлар, эндәшләр*

Болыт, болыт, килмә син,
Безнең юлны бүлмә син,
Син килгәч, без куркабыз,
Өйгә кайтып китәбез.

Әтисенә ай кебек,
Әнисенә көн кебек,
Апасына гөл кебек,
Бабасына туп кебек,
Килеп киткән кешеләргә
Чүп кадәр дә юк кебек.

## *Мәкальләр*

* Рәхмәт кемгә дә рәхәт.
* Кош — канаты белән, кеше дуслары белән көчле.
* Дустың булмаса — эзлә, тапсаң — югалтма.
* Кешегә иң кирәге — ягымлы чырай, җылы сүз.
* Татлы тел аюны да биетә.
* Теле татлының дусты күп.
* Тыйнаклык кешене бизи.

## Шигырьләр

**Әйдә, танышабыз**

Йә, әйдә, танышабыз,
Кулга-кул бирешәбез,
Исемне әйтешәбез,
Кул кысып күрешәбез.
Киң итеп елмай миңа,
Мин дә елмаям сиңа.
Туры итеп караштык,
Менә шулай таныштык.
Вәсимә Хәйруллина

**Иртә**

Бер ягымда — кызыл Кояш,
Бер кулымнан әни тоткан,
Бер ягымда — ап-ак Ай.
Бер кулымнан — әтием.
Мине озата баралар,
Шыпырт кына уйлап барам,
Адашмасын дип бугай.
Үзләренә әйтмимен.
Әни минем Кояш инде,
Әти Ай дип ышанам. Уң якта — Ай,
Сулда — Кояш, Ә мин кемгә охшаган?
Илсөяр Иксанова

### Үстерешле уеннар

**Иң җитез**

Уен мәйданчыкта оештырыла. Җиргә, бер-берсеннән ара калдырып, кыршаулар салына. Һәр бала бер кыршау эченә кереп баса. Алып баручы уртада басып тора. Ул: “Бер, ике, өч, йөгерегез!” – дип әйтүгә, балалар кыршауларыннан чыгып йөгерә башлыйлар. “Бер, ике, өч, өйгә таба йөгер!” – дигә команда әйтүгә, балалар кыршауларына кереп басалар. “Өй”сез калган уенчы киләсе уенда алып баручы була.

**Такси**

Ике бала зур кыршау эченә – берсенең артына икенчесе кереп басалар. Кулларын төшереп, кыршауны ике яктан тоталар. Алда басып торган бала – “такси йөртүче”, икенчесе – “пассажир”. Балалар бүлмә буйлап бер юнәлештә йөгереп йөриләр. Бераздан, юнәлешләрен үзгәртеп, тукталышлар ясап йөриләр, йөгерәләр.
Берникадәр вакыттан соң рольләрен алмаштыралар

| | |
|---|---|
| **Хәрәкәтле уеннар**<br>***Мин сикерәм, син кул чәбәклә***<br>Уйнаучылар, бер-берләренә карап, ике рәткә тезелеп басалар. Тәрбияче сигналы буенча беренче рәттәге балалар кул чаба башлыйлар, икенче рәттәгеләр бер урында ике аякта сикереп торалар (аяклар бергә, аяклар як-якка). 12-16 тапкыр сикергәннән соң балалар рольләрен алмашалар.<br>**Куяннар**<br>Бер бала “эт” итеп билгеләнә. Ул яшелчә бакчасын саклый. Калган балалар – “куяннар”. Идәнгә түгәрәкләр – “куяннарның өе” сызыла. Куяннар, ике аякта сикерә-сикерә, яшелчә бакчасында йөриләр, түтәлләр аша сикереп чыгалар. “Эт килә!” дигән сигналны ишетүгә, куяннар үз өйләренә йөгерәләр. Эт аларны куа. Тотылган куянны үзе белән алып китә. | |



# Туган тел атнасы

## Әти-әниләр өчен кулланма(4-5 яшь)

### *Җырлар, юаткычлар, эндәшләр*

* Ябалак, ябалак,
Йөрмә, чеби сагалап.
Чебиемне бирмәм,
Күземә күренмә, көш

Камка түти, кач, кач,
Алтын капкаң ач, ач.
Анаң салма пешерә,
Атаң ашап бетерә.

### *Мәкальләр*

* Әти-әни — чын дустым, дус-ишләрем — юлдашым.
* Ата-анасына игелек күрсәтмәгән,  олыгайгач, үзе дә игелек күрмәс.
* Әткәй — шикәр, әнкәй — бал.
* Бердәм өйдә бәрәкәт була.
* Яктылык — кояш янында, яхшылык — ана янында.
* Икмәкнең валчыгы да бездән олы, коеп ашама.
* Туган илем — туган өем.

| | |
|---|---|
| **Шигырьләр**<br>**Эшкә өндәү**<br>И сабыйлар! Эшләгез сез, иң мөкатдәс нәрсә — эш,<br>Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китерер җимеш.<br>Яшьлегеңдә күп тырышсаң, эшкә бирсәң чын күңел,<br>Каршыларсың картлыгыңны бик тыныч һәм бик җиңел.<br>Габдулла Тукай<br>**Кызыклы шәкерт**<br>— Әйдәле, Акбай! өйрән син, арт аягың берлә тор;<br>Аума, аума! туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!<br>— Ник газаплыйсың болай син, мин әле бик кечкенә;<br>Мин туганга тик ике айлап булыр, йә өч кенә.<br>Юк, кирәкми, мин өйрәнмим, минем уйныйсым килә;<br>Шул болыннарда ятасым, шунда ауныйсым килә.<br>— Ах, юләр маэмай! тырыш яшьләй, — зурайгач җайсыз ул:<br>Картаеп каткач буыннар, эш белү уңайсыз ул!<br>Габдулла Тукай | |
| **Үстерешле уеннар**<br>**Сарыкмы, кәҗәме?**<br>Тәрбияченең кулында рәсемнәр. Балалар бергәләп санамыш әйтәләр:<br>Берәү, икәү, өчәү, дүртәү,<br>Кырда йөрим, маллар көтәм.<br>Кемгә санап барып җитәм,<br>Шул буладыр көтүче.<br>Шул күрәдер рәсемне:<br>Сарыкмы ул, кәҗәме?<br>Санамыш ярдәмендә сайлап алынган бала, башкаларга күрсәтмичә генә, бер рәсемне тәрбияче кулыннан ала. Рәсемдәге хайван булып кылана, шуның тавышы белән кычкыра. Балалар кайсы хайван икәнен танып әйтергә тиешләр. Беренче булып дөрес җавап биргән бала аннан соңгы рәсемне ала. | |

## Хәрәкәтле уеннар

### Куышу

Бер бала урындыкта утырып тора. Калган балалар белән тәрбияче, түбәндәге сүзләрне әйтә-әйтә, әлеге бала янына киләләр: Без — күңелле, шат балалар, — Яратабыз уйнарга. Без качабыз, син, әйдә, ку, Тырыш куып тотарга. Соңгы сүзләрдән соң балалар йөгереп китәләр, утырып тор- ган бала аларны куа. Тотылган бала урындыкка утыра. Уен шулай дәвам итә.

### Йонлач көчек

Уенга берничә баланы чакырыгыз. Бер баланы көчек итеп билгеләгез. Ул, алга сузылган кулларына башын куеп, идәндәге паласка ята. Балалар әкрен генә аның янына килә башлыйлар, ә сез бу вакытта түбәндәге сүзләрне әйтәсез: Йонлач көчек йоклап ята, Җиргә төртеп борынын. Йокламасын, уянсын, Безнең белән уйнасын. «Көчек» сикереп тора, балаларны куа башлый. Балалар төрлесе төрле якка йөгереп китәләр һәм «көчек»тән качалар. Барлык балалар да качып беткәч, «көчек» кире паласка барып ята



# Ватанны саклаучылар көне

*Әти-әниләр өчен кулланма(4-5 яшь)*

## Мәкальләр

* Әти-әни — чын дустым, дус-ишләрем — юлдашым.
* Ата-анасына игелек күрсәтмәгән,  олыгайгач, үзе дә игелек күрмәс.
* Әткәй — шикәр, әнкәй — бал.
* Бердәм өйдә бәрәкәт була.
* Яктылык — кояш янында, яхшылык — ана янында.
* Икмәкнең валчыгы да бездән олы, коеп ашама.
* Туган илем — туган өем.
* Дустың булмаса — эзлә, тапсаң — югалтма.
* Кешегә иң кирәге — ягымлы чырай, җылы сүз.
* Татлы тел аюны да биетә.
* Теле татлының дусты күп.
* Тыйнаклык кешене бизи.
* Бер ялганласаң, икенче дөрес сүзеңә дә ышанмаслар.

**Шигырьләр**

**Солдатлар**

Бабай да солдат булган,
Әти дә солдат булган.
Зур абый да, солдат булып,
Ил чикләрендә торган...

Кече абый солдат булып
Китте быел яз гына,
Мин үзем дә солдат булам,
Үсим әле аз гына.

Клара Булатова

**Туган илнең улы мин**

Бабайның да  улы мин,
Әбинең дә улы мин,
Әтинең дә улы мин,
Әнинең дә улы мин,
Аларның уң кулы мин.
Бабай кебек булырмын,
Әби кебек булырмын,
Әти кебек булырмын,
Әни кебек булырмын,
Бернигә дә карамый.
Шулай булмый ярамый —
Соң бит инде олы мин,
Туган илнең улы мин!

Роберт Миңнуллин

**Үстерешле уеннар**

**Сарыкмы, кәҗәме?**

Тәрбиячендең кулында рәсемнәр. Балалар бергәләп санамыш әйтәләр:

Берәү, икәү, өчәү, дүртәү,
Кырда йөрим, маллар көтәм.
Кемгә санап барып җитәм,
Шул буладыр көтүче.
Шул күрәдер рәсемне:
Сарыкмы ул, кәҗәме?

Санамыш ярдәмендә сайлап алынган бала, башкаларга күрсәтмичә генә, бер рәсемне тәрбияче кулыннан ала. Рәсемдәге хайван булып кылана, шуның тавышы белән кычкыра. Балалар кайсы хайван икәнен танып әйтергә тиешләр. Беренче булып дөрес җавап биргән бала аннан соңгы рәсемне ала.

## Хәрәкәтле уеннар

### Мин качам, син тот

Уйнаучылар кулга-кул тотынышып, парлап басалар. Алда, аларга каршы, уенны алып баручы баса. Балалар, бергәләп: Без, балалар, яратабыз качыш-тотыш уйнарга. Әйдә, безне тотып кара, көчең җитсә тотарга, — дип әйтүгә, беренче булып басып торган пар кулларын ычкындыра, һәм икесе ике якка йөгереп китә. Уенны алып баручы аларның берсен тотарга тиеш. Тотылган кеше уенны алып баручы була.

### Ачкычлар

Мәйданчыкта (яисә идәндә) түгәрәкләр сызыла. Уйнаучылар шул түгәрәкләргә кереп басалар. Арадан берсе уенны алып баручы була. Ул уенчыларның берәрсе янына килеп сорый: «Ачкыч кайда?» Тегесе җавап бирә: «Алсудан сора, ул әйтер сиңа». Алар сөйләшкән арада, калган балалар бер-берсе белән урыннарын алыштыралар (бер түгәрәктән икенче түгәрәккә күчәләр). Алып баручы да тиз генә берәр буш түгәрәк эченә кереп өлгерергә тырыша. Түгәрәксез калган бала уенны алып баручы була. Уен шулай дәвам итә.



# 8 Март – әни бәйрәме

*Әти-әниләр өчен кулланма(4-5 яшь)*

## *Бишек җыры*

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу;
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып җитәр ул.

Йокла, улым, йом күзен,
Йом, йом күзең, йолдызым;
Кичтән йокың кала да,
Елап үтә көндезең.

Әлли бәлли көйләрмен
Хикәятләр сөйләрмен
Бәхетле бул диярмен
Синең төләкне төләрмен

Гыйззәтем син, кадрем син,
Минем йөрәк бәгърем син;
Куанычым, шатлыгым
Тик син минем, син, син, син!

**Шигырьләр**

**Әниләр бәйрәме**

Кояш көлә, мин елмаям,
8 нче Март бүген.
Бүген әниләр бәйрәме,
Шуңа күңелем шат минем.
Кайсын юам, кайсын җыям,
Чиста булсын, ак булсын.
Әниләрнең күңеледәй
Бөтен нәрсә пакь булсын.
— Бәйрәм бүген, бәйрәм! — диеп,
Бар дөнья көлеп торсын.
Әни бәйрәме икәнен
Әти дә белеп торсын,
Әти дә көлеп торсын!

Саҗидә Сөләйманова

**Минем әнием**

Мине әнием көн саен
Бакчага үзе илтә,
Мин бакчада уйнап калам,
Әнием эшкә китә.

Оста тегүче булып
Танылган ул эшендә,
Аның теккән киеме
Бик килешә кешегә.

Без, нәниләр, яратабыз
Матур күлмәк кияргә,
Рәхмәт безнең апаларга,
Тегүче әниләргә.

Әминә Бикчәнтәева

**Җырлы биюле уен “Гөл утыртканда”**

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Уртада башына кызыл чәчәкләр белән бизәлгән тәкыя кигән бер бала чүгәләп утыра. Аның өстенә карарак төстәге җәймә ябалар. Әлеге бала тирәсендә берничә бала гөл утырткан хәрәкәтләр ясыйлар. Түгәрәктәге барлык башка балалар түбәндәге җырны җырлыйлар:

Балчык йомшартып утыртамын гөл,
Шытып, яшәреп чыгар әле ул.
Көн саен карап, мин сибәрмен су,
Чәчкә атар ул кызылсу-алсу.
Канатын җәеп, аңа кунар бер былбыл.
Моңланып сайрар: – Син, дип, матур гөл!

Җыр тәмам булганнан соң, җәймә астыннан «гөл» күтәрелә. Сандугач киемендәге бер бала түгәрәккә кереп җырлый: Ай-яй, матур гөл, ямьле, ал-кызыл.
Сөямен, сиңа гашыйк мин, былбыл.
Җырлар тезәмен сиңа, ал гөлем,
Син үскәндә тик, ямьле бу илем.

| | |
|---|---|
| **Хәрәкәтле уеннар**<br>***Аю***<br>Уенчылар бер-берсенә карап, түгәрәкләнеп басалар. Бер уенчы, кулына ярты метр чамасындагы бау тотып, түгәрәк тышында йөри. Ул: «Аю китте, күрдеңме?» — дип, иптәшләренең берсенә бау белән сугып ала, һәм үзе йөгерә. Сугылган кеше, аны куып җитеп, бауны алырга тиеш. Тота алмаса, ул уеннан чыга, һәм киресенчә, тота алса, бауны алдырган кеше уеннан чыга. Уен түгәрәктә бер генә кеше калганчы дәвам итә. Ул җиңүче була.<br>***Чәчәкләр, җилләр***<br>Бер-берсеннән 2 м ераклыкта ике сызык сызыла. Шул сызыклардан 10—15 м ераклыкта тагын ике сызык сызарга. Уенда катнашучылар ике төркемгә: «чәчәкләр» һәм «җилләр»гә бүленәләр һәм эчке сызыклар артына бер-берсенә йөзләре белән тезелешеп басалар. Уенны «чәчәкләр» башлый. Алар һәрберсе үзләренә берәр чәчәк исеме алалар. «Җилләр, җилләр. Безнең исемнәребезне беләсезме?» — диләр алар. «Җилләр» чәчәк исемнәрен әйтә башлыйлар. Исеме аталган «чәчәк», йөгереп килеп, «җилләр» төркеменә күчә бара. Уен шулай дәвам итә. | |



# *Кеше һәм математика*

*Әти-әниләр өчен кулланма(4-5 яшь)*

***Санамышлар***

* Әнә тора бер чыпчык,
Менә тора бер чыпчык,
Артык булсаң, очып чык!

* Чар, чар, чыпчыклар,
Бирсәгез лә орчыклар.
Анда чык, монда чык,
Саубуллаш та моннан чык.

* Кулда —уймак,
Табада — коймак,
Мичтә — бәлеш,
Ал даябыш.

* Әке, бәке,
Кыек сәке,
Эремчек.
Син калып тор,
Ә син чык.

| | |
|---|---|
| **Шигырьләр**<br>Менә сиңа уң кулым.<br>Менә сиңа сул кулым<br>Уң кулым, сул кулым.<br>Менә сиңа куш кулым.<br><br>**Беләсеңме?**<br>Йөз чикләвек җыйдым мин,<br>Биштән берен ашадым.<br>Калганының яртысын<br>Кортлы булгач ташладым.<br>Энем белән сеңелемә<br>Бүлеп бирдем калганын.<br>Беләсеңме аларның<br>Ничәшәрне алганын? (энесе белән сеңлесенә 20шәр чикләвек биргән)<br><br>**Нинди тизлектә?**<br>Гали белән Нургали<br>Йөри иде гел бергә.<br>Оныткан бит Нургали<br>Галиләргә керергә.<br>Бара торгач, Нургали<br>Ике чакрым китkән , ди<br>Соң чыкса да ун минут,<br>Гали куып җиткән, ди<br>Исе китеп аңарга,<br>Тел шартлаткан Нургали.<br>Яле, нинди тизлектә<br>Чапкан инде бу Гали. (Сәгатенә 12 чакрым тизлектә) | |
| **Ял минуты**<br>**Без инде хәзер зурлар**<br><br>Без инде хәзер зурлар, — аяк очларына басып,<br>Күп эшли безнең куллар. — кулларын югары күтәрәләр, кулларын төрле якка хәрәкәтләндерәләр<br><br>Без идән дә юабыз, — иелеп, идән юу хәрәкәтләре<br>Без керләр дә уабыз, — ясыйлар, куллар белән кер «уалар»,<br>Гөлләргә су сибәбез. — гөлгә су сибү хәрәкәте күрсәтәләр<br><br>Менә шундый уңган без, — аяк очларына басып,<br>Менә шундый булган без. — түгәрәктә әйләнәләр | |

| | |
|---|---|
| **Хәрәкәтле уеннар**<br>**Коңгызлар**<br>Уйнаучы балалар коңгызлар итеп билгеләнә. Тәрбияченең «Коңгызлар очалар» дигән сүзләреннән соң уйнаучылар «жу- жу-жу» дип жуылдап, бүлмә буйлап төрле юнәлештә йөгереп китәләр. Бу вакытта тәрбияче сөйли: Коңгызлар оча жуылдап, Бж-бж, бж-бж быжылдап. Оча торгач ардылар, Идәнгә егылдылар. «Егылдылар» сүзеннән соң балалар аркаларына яталар һәм аяк-куллары белән төрле хәрәкәтләр ясыйлар. Коңгызлар ял иттеләр, Тагын очып киттеләр. Балалар, торып, тагын очу хәрәкәтләре ясыйлар.<br>**Кечкенә туплар**<br>Балалар, түгәрәк ясап, урындыкларда утырып торалар. Рәттән утырган 2 балага тәрбияче берәр кечкенә туп бирә. Бер бала тупны уң якка, икенчесе сул якка җибәрә (балалар туплар- ны бер-берләренә бирәләр). Ике туп «очрашкач», туплы бала- лар икесе ике якка йөгереп китәләр. Калган балалар бу вакытта «йөгердек, йөгердек» дип кабатлыйлар, кулларын чәбәклиләр. Ике бала, кара-каршы очрашкач, тупларын тәрбиячегә тапшы- ралар. Ул аларны башка балаларга бирә һәм уен дәвам итә. | |



# *Нәзүрүз җитми яз булмый*

*Әти-әниләр өчен кулланма(4-5 яшь)*

**Нәүрүз мөбарәк булсын!**
**(Халык авыз иҗаты)**

Кыш китте, яз килде,
Үрдәк белән каз килде,
Былбылдан аваз килде
Нәүрүз мөбарәк булсын!

Абзый, эшең уң булсын,
Теләгәнең юш булсын,
— Күңелләрең хуш булсын
Нәүрүз мөбарәк булсын!

**Шигырьләр**

Карга боткасы
Җиребезгә язлар килгәч,
Кошлар кайткач ерактан,
«Карга боткасы» пешергән
Халкыбыз чын йөрәктән.
Бу бәйрәм безнең көннәргә
Килгән, гасырлар үтеп.
Каргалар да, без дә аны
Һәр ел алабыз көтеп.

**Минем әнием**
Быел да менә пешердек:
Салдык тәмле ярмалар,
Сыйланыгыз, туган якны
Сагына белгән каргалар!
Изге йола, еллар кичеп,
Киләчәккә дә барсын.
Үз ботказарын ашарга,
Берүк, каргалар калсын!
Йолдыз

**Җырлы биюле уен “Гөл утыртканда”**

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Уртада башына кызыл чәчәкләр белән бизәлгән тәкыя кигән бер бала чүгәләп утыра. Аның өстенә карарак төстәге җәймә ябалар. Әлеге бала тирәсендә берничә бала гөл утырткан хәрәкәтләр ясыйлар. Түгәрәктәге барлык башка балалар түбәндәге җырны җырлыйлар:

Балчык йомшартып утыртамын гөл,
Шытып, яшәреп чыгар әле ул.
Көн саен карап, мин сибәрмен су,
Чәчкә атар ул кызылсу-алсу.
Канатын җәеп, аңа кунар бер былбыл.
Моңланып сайрар: – Син, дип, матур гөл!

Җыр тәмам булганнан соң, җәймә астыннан «гөл» күтәрелә. Сандугач киемендәге бер бала түгәрәккә кереп җырлый: Ай-яй, матур гөл, ямьле, ал-кызыл.
Сөямен, сиңа гашыйк мин, былбыл.
Җырлар тезәмен сиңа, ал гөлем,
Син үскәндә тик, ямьле бу илем.

**Хәрәкәтле уеннар**

**Яулык алыш**

Бу уен күбесенчә кыз балалар тарафыннан уйнала. Кызлар бер урынга түгәрәкләнеп басалар да бер кешене яулык җыючы итеп сайлап куялар. Ул уртага чыгып баса да:

Талым, талым, талчыбык, уртасында бал чыбык,
Ал яулык, гөл яулык, бир син миңа бер яулык, —

дип такмаклый-такмаклый, барлык кызлардан да яулык җыеп чыга. Җыеп бетергәч, яулык хуҗаларына берәм-берәм җәза бирелә. Җәзадан соң уен тагын яңадан башлана.

**Башмакчы**

Балалар түгәрәк ясап басалар. Өлкәннәрдән берәү уенны оештыручы була. Ул, кулына бер башмак алып (уйнаучы балаларның аяк размерыннан башмак зуррак булырга тиеш), уртага баса. Җырлый:

Төрле һөнәр беләбез, матур итеп тегәбез;Асыл төсле җепләр белән башмак башын чигәбез.

Балалар аңа каршы, түгәрәк буйлап йөреп, җыр җырлыйлар:

Әй башмакчы, башмакчы, үзең — оста такмакчы. Син җырлама такмагың, бир кияргә башмагың.

Балалар җырлап бетергәч, алып баручы башмакны 2 бала арасына куя һәм аларның иңнәренә кагыла. 2 бала икесе ике якка түгәрәк буйлап йөгереп китәләр. Кем беренче килеп җитә,
шул башмакны кия. Ул «башмакчы» була. Уен яңадан башлана.



# *Кошлар безнең дусларыбыз*

***Әти-әниләр өчен кулланма(4-5 яшь)***

## *Бишек җыры*

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу;
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып җитәр ул.

Йокла, улым, йом күзен,
Йом, йом күзең, йолдызым;
Кичтән йокың кала да,
Елап үтә көндезең.

Әлли бәлли көйләрмен
Хикәятләр сөйләрмен
Бәхетле бул диярмен
Синең төләкне төләрмен

Гыйззәтем син, кадрем син,
Минем йөрәк бәгърем син;
Куанычым, шатлыгым
Тик син минем, син, син, син!

**Шигырьләр**

**Әниләр бәйрәме**

Кояш көлә, мин елмаям,
8 нче Март бүген.
Бүген әниләр бәйрәме,
Шуңа күңелем шат минем.
Кайсын юам, кайсын җыям,
Чиста булсын, ак булсын.
Әниләрнең күңеледәй
Бөтен нәрсә пакь булсын.
— Бәйрәм бүген, бәйрәм! — диеп,
Бар дөнья көлеп торсын.
Әни бәйрәме икәнен
Әти дә белеп торсын,
Әти дә көлеп торсын!

Саҗидә Сөләйманова

**Минем әнием**

Мине әнием көн саен
Бакчага үзе илтә,
Мин бакчада уйнап калам,
Әнием эшкә китә.

Оста тегүче булып
Танылган ул эшендә,
Аның теккән киеме
Бик килешә кешегә.

Без, нәниләр, яратабыз
Матур күлмәк kияргә,
Рәхмәт безнең апаларга,
Тегүче әниләргә.

Әминә Бикчәнтәева

**Җырлы биюле уен “Гөл утыртканда”**

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Уртада башына кызыл чәчәкләр белән бизәлгән тәкыя кигән бер бала чүгәләп утыра. Аның өстенә карарак төстәге җәймә ябалар. Әлеге бала тирәсендә берничә бала гөл утырткан хәрәкәтләр ясыйлар. Түгәрәктәге барлык башка балалар түбәндәге җырны җырлыйлар:
Балчык йомшартып утыртамын гөл,
Шытып, яшәреп чыгар әле ул.
Көн саен карап, мин сибәрмен су,
Чәчкә атар ул кызылсу-алсу.
Канатын җәеп, аңа кунар бер былбыл.
Моңланып сайрар: – Син, дип, матур гөл!
Җыр тәмам булганнан соң, җәймә астыннан «гөл» күтәрелә. Сандугач киемендәге бер бала түгәрәккә кереп җырлый: Ай-яй, матур гөл, ямьле, ал-кызыл.
Сөямен, сиңа гашыйк мин, былбыл.
Җырлар тезәмен сиңа, ал гөлем,
Син үскәндә тик, ямьле бу илем.

| Хәрәкәтле уеннар | |
|---|---|
| ***Аю***<br>Уенчылар бер-берсенә карап, түгәрәкләнеп басалар. Бер уенчы, кулына ярты метр чамасындагы бау тотып, түгәрәк тышында йөри. Ул: «Аю китте, күрдеңме?» — дип, иптәшләренең берсенә бау белән сугып ала, һәм үзе йөгерә. Сугылган кеше, аны куып җитеп, бауны алырга тиеш. Тота алмаса, ул уеннан чыга, һәм киресенчә, тота алса, бауны алдырган кеше уеннан чыга. Уен түгәрәктә бер генә кеше калганчы дәвам итә. Ул җиңүче була.<br>***Чәчәкләр, җилләр***<br>Бер-берсеннән 2 м ераклыкта ике сызык сызыла. Шул сызыклардан 10—15 м ераклыкта тагын ике сызык сызарга. Уенда катнашучылар ике төркемгә: «чәчәкләр» һәм «җилләр»гә бүленәләр һәм эчке сызыклар артына бер-берсенә йөзләре белән тезелешеп басалар. Уенны «чәчәкләр» башлый. Алар һәрберсе үзләренә берәр чәчәк исеме алалар. «Җилләр, җилләр. Безнең исемнәребезне беләсезме?» — диләр алар. «Җилләр» чәчәк исемнәрен әйтә башлыйлар. Исеме аталган «чәчәк», йөгереп килеп, «җилләр» төркеменә күчә бара. Уен шулай дәвам итә. | |



# ***Җиңү көне***

***Әти-әниләр өчен кулланма(4-5 яшь)***

Баш бармак,
Балан ияк,
Урта тияк,
Әби-чәби,
Нәни бәби.

* Ай, диләр, вай, диләр,
Бу абзый бик бай, диләр.
Бу абзыйның капчыгында
Баллы прәннек бар, диләр.

| | |
|---|---|
| **Кояшлы ил**<br>Кояшлы ил — безнең ил,<br>Күге аның гел аяз.<br>Кыш китерсә Кыш бабай,<br>Чәчәк алып килә Яз.<br>Сандугачлы урманы,<br>Ашлык тулы кырлары,<br>Бөтен җирдә яңгырый<br>Безнең бәхет җырлары.<br><br>Һавасы да, җире дә,<br>Салават күпере дә,<br>Яңгыры да, кары да —<br>Безгә якын бары да...<br>Әхмәт Рәшит | |
| **Үстерешле уен “Без урманга барган идек...”**<br>Балалар түгәрәктә басып торалар. Бер бала башкаларга арты белән баса. Тәрбияче күз караша белән генә түгәрәктәге бер балага ымлый. ул икенче бүлмәгә чыга. Балалар бергәләп кабатлыйлар:<br>Без урманга барган идек, югалттык беребезне,<br>Әйтеп бирче безгә, Риназ, югалттык соң без кемне?<br>Риназ, борылып карап, кем юклыгын әйтә. Дөрес әйтмәсә, тагын бер кат сынап карыйлар, дөрес әйтсә, урыннарын алышалар. | |

*Хәрәкәтле уеннар*

**Куышу**

Уен мәйданчыгының каршы якларына ике туры сызыла. Болар – балаларның «өйләре». Барлык балалар бер туры сызыкның артына (өй эченә) басалар. Турылар арасында уйнаучыларның берсе басып тора. Өй эчендә торучы балалар түбәндәге сүзләрне әйтәләр: Без, балалар, яратабыз йөгереп, сикереп уйнарга. Әйдә, безне куып кара, Көчең җитсә тотарга, Тот! Тәрбияченең «Бер, ике, өч, инде монда көч!» дигән сүзеннән соң барысы да, өйдән чыгып, каршыдагы өйгә йөгерәләр. Ике өй арасындагы бала йөгерүче балаларны тота. 2–3 бала тотылганнан соң, икенче тотучы сайлана, һәм уен яңадан башлана.

**Туп кайда?**

Санамыш ярдәмендә уенны алып баручы сайлана. Балалар түгәрәккә басалар. Алып баручы уртада басып тора. Уйнаучылар, алып баручыга сизелмәслек итеп, арттан туп бирешәләр. Әгәр алып баручы тупның кемдә икәнен сизсә, аның янына килеп: «Кулларыңны күрсәт», – ди. Әлеге бала, учларын өскә каратып, кулларын югары күтәрә. Әгәр аның кулында туп булса (яки ул тупны төшереп җибәрсә), уен тәмам була. Әгәр туп анда булмаса, ул кулларын яңадан артка куя, һәм уен дәвам итә. Туп белән 2–3 бала тотылгач, алып баручы алышына.



# *Исәнме, җәй!*

***Әти-әниләр өчен кулланма(4-5 яшь)***

***Эндәшләр***

* Кәк-күк, кәк-күк,
Монда гөмбә бик күп.
Бик күп, бик күп,
Кәк-күк, кәк-күк.

* Болыт, болыт, килмә син,
Безнең юлны бүлмә син,
Син килгәч, без куркабыз,
Өйгә кайтып китәбез.

**Шигырьләр**

**Уяталар**

Кояш чыккан да көлеп,
Алтын түбәтәй киеп,
Уята мине килеп:
— Тор, малай, әй, тор!
— кем анда  диеп.

Сандугач та уята,
Гел үртәп аптырата.
— Чут, чут, чут, — ди, —
Төшкәчә йоклап ята?

Әтәч тә йокы бирми,
Һич тыныч кына йөрми,
— Кикрикүк! — дип, —
Кикрикүк!
Уята мине иртүк.

Уяталар һәрьяклап,
Әби сөя кочаклап,
- Сине яраталар, — ди, —
- Шуңа уяталар, — ди.

Резеда Вәлиева

**Матур уен**

Балалар кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар. Бер бал уртага баса

Син уртада без кырыйда
Әйләнәбез түгәрәк.
Уеныбыз матур булсын,
Күңел ачыйк бергәләп.

*Балалар түгәрәк буйлап жырлап йөриләр,*

Таянабыз билләргә,
Тотынабыз биергә.

*туктап, түгәрәк уртасына борылалар, кулларын билгә куялар,*

Тыпыр-тыпыр тыпырдатып
Әйләнәбез без бергә.

*аякларын тыпырдаталар, парлашып әйләнәләр.*

## Хәрәкәтле уеннар

***Тота бел***

Балалар тәрбияче белән бергә түгәрәкләнеп тезеләләр һәм бер-берсенең кулларына тотынышалар. Түгәрәк уртасына әйдәүче баса. Балалар түгәрәк буенча уңга яки сулга таба әйләнеп йөриләр һәм түбәндәге сүзләрне көйләп әйтәләр: “Без, балалар, яратабыз уйнарга, йөгерергә, җырларга, әйдә, безне куып кара, көчең җитсә тотарга, Тот!” Соңгы «Тот!» дигән сүзне әйтү белән, балалар мәйданчык (бүлмә) буйлап йөгерә башлыйлар, әйдәүче аларны куып тотарга тырыша. Тотылган балалар вакытлыча уеннан чыгалар. Әйдәүче 3–5 баланы тоткач, уен тәмамлана. Уйнаучылар арасыннан яңа әйдәүче сайлана (тотылган балалар сайлана алмый). Яңа уенга үткән уенда тотылган балалар барысы да яңадан катнаша. Уен 3–5 тапкыр кабатлана.

**Җитез балалар**

Балалар урындыкларда утырып торалар. Идәнгә куелган кәрзингә уртача зурлыктагы 5–6 туп салына. Балаларның бер өлеше (туп санына карап), утырган урыннарыннан торып, бер  рәткә тезеләләр. Тәрбияче: «Бер, ике, өч», – ди дә кәрзиндәге тупларны тәгәрәтеп җибәрә. Балалар туплар артыннан йөгерәләр. Һәр бала бер тупны тотып, тәрбиячегә китереп бирә. Тәрбияче балаларны мактый. Туплар артыннан йөгергән балалар үз урыннарына килеп утыралар, ә алар урынына башка балалар чыга.